# ХАЛЫК
# ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **23.11.2020 ел**

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкә авыл җирлеге составына керүче
Бәйрәкә авылында 2021 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлегендә гражданнар җыены

**К А Р А Р И Т Т Е:**

Бәйрәкә авыл җирлеге территориясендә 2021 елда, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, Бәйрәкә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә, 2 төркем инвалидлар өчен түләү суммасын 250 сум күләмендә киметеп, үзара салым кертергә.

1. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Бәйрәкә авылында юлларны грейдерлау, кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

-Бәйрәкә торак пунктындагы Ютазы урамы буенча юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (юл төзелеше: вак таш, асфальт сатып алу, нигез әзерләү, ташу, җәю, эшләр өчен түләү);

- Бәйрәкә торак пунктында административ бина территориясен төзекләндерү (койма алу һәм урнаштыру);

- Бәйрәкә торак пунктында Абдуллин урамындагы зират коймасын ремонтлау ( төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Бәйрәкә торак пунктында Кооперация урамындагы зират коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Бәйрәкә торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү);

- коры агачларны, куакларны кисү; Бәйрәкә торак пункты территориясен җыештыру (килешү буенча эшләр өчен түләү).

Халык җыенында рәислек итүче,
Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы А.О.Әхмәтшина